№90 (194)
15 ноябрь
1997 ел

Көмеш кыңгырау

1996 елның 1 гыйнварыннан чыга башлады

Чаллы шәһәре ✿ Балалар һәм яшүсмерләр газетасы

Сөмбелә, исәнме һәм... хуш!

"Сөмбелә" бәйрәме 50нче балалар бакчасында да булып үтте. Балаларны һәм әти-әниләрне зәвык белән бизәлгән залда бәйрәмнең хуҗасы Сөмбелә һәм Уңыш бабай каршы алды. Балалар бик матур итеп җырлар җырладылар, биеделәр, сәнгатьле итеп шигырьләр укыдылар, уеннар уйнадылар. Аннары табышмаклар, мәкальләр әйтешеп, көчләрен сынаштылар. Бәйрәм һәрбер баланың һәм әти-әниләрнең күңелендә калырлык булып үтте.

Гомумән, бу бакчада татар халкының телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен үстерүгә нык игътибар бирелә. Юкка гына 1995 елда үткәрелгән "Туган телем - чиксез хәзинә" фольклор бәйрәмендә беренче урынны алмадылар.



Зур рәхмәт белән әти-әниләр: Г.Т. НИКИТИНА, Ф.А. КӘРИМОВ һәм башкалар.

Фәрит Кәримов фотолары.

Бик күңелле булды!

16нчы татар мәктәбендә 1 сыйныф укучылары катнашында үткән Сөмбелә бәйрәме бигрәк тә күңелле үтте. Залдагы төрле җиләк-җимеш, яшелчә булып киенгән укучылар бигрәк тә матурлар иде инде. Сөмбелә бәйрәмен үткәрү өчен балалар һәм яшүсмерләр үзәгеннән Алия Рәхмәтуллина җитәкләгән җырчы кызлар килгән.

Җыр-бию бәйрәм барышында тынып тормады. Гөлкәй Сәйфуллина бәрәңге образын искиткеч осталык белән башкарды. Бәрәңгегә багышланган төрле табышмаклар, мәкальләр, уеннар балаларның күңеленә хуш килде. Элиза Кәримова, Зөмәрә Сираҗиевалар кыяр һәм помидор ролендә уйнадылар. Тәмле салатлар, ашлар пешерү, тозлау өчен иң кирәкле яшелчәләр булуын нәниләр бик яхшы исбат иттеләр. Суфия Гыйләҗиева һәр көн кирәк булган кишер образын балаларга бик кызыклы итеп җиткерде. 1 сыйныф укучыларының гомумән, яшелчә, җиләк-җимеш турында күп белүләре күренде.

Ямь өстенә ямь өстәп, 148нче балалар бакчасыннан килгән нәни җырчылар: Миләүшә Кәримова, Марат Әкиямов башкарган җырлар һәркемгә ошады.

Бәйрәм бик күңелле үтте. Һәр баланың йөзендә шатлыклы елмаю иде.

Диләрә ХАЛИКОВА.

Белдерү!

Дуслар! Былтыр "Көмеш кыңгырау" редакциясе "Бизнесцентр" (җитәкчесе - Владимир Григорьевич Иванов) белән берлектә "Лотерея уены"н бик матур үткәргән иде, хәтерлисезме?! Былтыр үткәргәнгә, быел ник кычкырасыз, дисезме?

Чөнки "Лотерея уены"н быел да үткәрәчәкбез. Уенда нәкъ былтыргы кебек газетабызга тулы бер елга язылучылар гына катнаша. Язылыгыз һәм квитанциягезне югалтмагыз. Уенның кайчан буласын алдагы саннарда хәбәр итәрбез.

Безнең конкурс

"Төсләр балкышы"

Исәнме, "Көмеш кыңгырау!"

Сезгә Тукай районы, Казаклар авылында яшәүче Вәҗиева Гөлназ хат яза. Мин Теләнче-Тамак мәктәп-гимназиясенең 5"Г" сыйныфында укыйм. Буш вакытымда төрле кызыклы мизгелләрне фотосурәткә төшерергә яратам. Сезнең "Төсләр балкышы" дигән конкурска 2 фотомны җибәрәм. Мин беренче фотомны (песи белән тавык төшкән) болай дип атадым.



"Хуҗабикә кайда йөри икән? Ашыйсылар бик килә!"

Икенче фотома (бәйдәге эт белән песи) шигырь юллары яздым.



Әйдә, дустым аңлашыйк,
Синең белән дуслашыйк.
Бәйдән ничек ычкынуны
Икәү бергә уйлашыйк.

Сезгә сәламнәр белән ГӨЛНАЗ.

Редакциядән: Гөлназның ике фотосы да төсләр белән балкып тора. Эт белән песи оҗмах кочагында яталар мыни?! Ямь-яшел үлән арасында комач-кызыл гөлләр күренеп тора. Песинең күзләре зәңгәр, эт-җирән-сары төстә.

"Көмеш кыңгырау"ның "Сан-Марко" фотостудиясе белән берлектә үткәрелгән конкурсы дәвам итә. Җиңүчеләрне әйбәт бүләкләр көтә (төсле телевизор, видеомагнитофон, радиомагнитола һәм кызыксындыру призлары). Төп шарт: төсле фотолар "Сан-Марко"да проявить ителгән булырга тиеш.

Адресы: ГЭС бистәсе, 10/4"Б".

Төсле фотоларга төшерү мөмкинлеге булган һәркем бәхетен сыный ала.

Күрәзә төгәлләнде

Ниһаять белдек: Югары Ослангагы бердәнбер абунәчебез - Җиһаншина Розалия Әнвәровна икән. Ул районгагы мәгариф идарәсенең фильмотекасында эшли.

Шулай итеп, күрәзәдәге вариантларның берсе дә аңа туры килми: укытучы да, китапханәче дә һ.б.лар да түгел ул. Шулай булгач, редакция бүләкләрен дә бирәүгә дә җибәрми диеп,йомгак ясадык. Тик без алдан әзерләп куйган бүләкләр "кычкыра" гына бит: җибәрегез, яткырмагыз безне редакциядә, диләр.

Шуннан, без болай фикер йөрттек. Розалия Әнвәровнаның ике баласы бар икән. Башлангыч сыйныфларда укыйлар, икән. Димәк, мәктәп укучысы диген фараз дөрес булып чыга. Мәктәп укучысы диген җавап белән иң беренчеләрдән булып килгән 4 хат иясе җиңүчеләр итеп табылдылар:

Марат Закиров - 9нчы мәктәпнең, 7нче сыйныф укучысы.

Марат беренчеләрдән дә беренчесе булып дөрес җавап биргәнгә, редакция аңа иң зур бүләкне - сәгатьле радиоалгычны бирә.

Илдар Шәмсемөхәммәтов, Минзәлә районы, Усай авылы,

Эльвира Яруллина, 29нчы мәктәп-лицей.

Ильмир ГАЛИМОВ, Мөслим районы, Керәшен-Шуран авылы.

Бу күрәзәчеләребезгә дә кызыксындыру бүләкләре җибәреләчәк.

Кадерле дуслар! Уеныбызда катнашкан өчен рәхмәт сезгә.

Чыршы бәйрәме

(Пинче кечкенәләр төркеме өчен)

Балалар тәрбияче апалары белән музыка астында залга үтәләр. Чыршыны әйләнеп узалар, утыралар.

Җыр җырлап Кар кызы керә.

Кар кызы (залдагыларны күреп) Исәнмесез барыгыз да. Хәерле көн, нәни дусларым. Мин, Кар кызы. Таныдыгызмы? Сезгә кунакка, чыршы бәйрәменә килдем. (Чыршыга игътибар итә). Ай-яй-яй, Кыш бабай сезгә нинди матур чыршы җибәргән. Килегез әле, карагыз. Ялтыравык уенчыклар эленгән. Нәрсәләр генә юк. (Бергәләп чыршыны карыйлар, мактыйлар).

Кар кызы. Тагын да яктырак, күңеллерәк булсын өчен бер генә нәрсә җитми. Утлары юк. Әллә бергәләп яндырабызмы? Ягез әле нык итеп кул чабыгыз. Бер, ике, өч.

Балалар кул чабалар, чыршының уты яна. Кул чабудан туктыйлар. Сүнә. Берничә тапкыр кабатлана.

Кар кызы. Балалар, чыршы белән исәнләшергә онытканбыз. Шуңа сүнә ул. Матур итеп исәнләшик әле.

Балалар. Исәнме, чыршы! (Утлар яна).

Чыршы (магнитофонда) Исәнмесез!

Көттем сезне, нәни дуслар,
Бик сагынып, өзелеп.
Җырлагыз сез минем турыда
Матур җырлар өздереп.

Җыр "Чыршыкай". Г.Гәрәева сүзләре һәм көе.

Кар кызы. Яшел чыршы тирәсенә
Якынрак басыгыз.
Уйнап-көлеп, җырлап-биеп
Бүген күңел ачыгыз.

1 бала. Бик күңелле, рәхәт безгә
Чыршы синең янында.
Елмай әле, елмай шулай
Тагын, тагын, тагын да.

2 бала. Җырлар җырлап әйләнәбез
Бүген синең тирәңдә.
Үзең матур, үзең чибәр
Кадәмый бер энәң дә.

3 бала. Бүген синең янына
Җыелган дусларың.
Аю, тиен, куяннар,
Әллә кемнәр бар тагын.

4 бала. Сиңа карап сокланабыз,
Шаярабыз, көләбез.
Кем кем инде, ә без менә
Бәйрәм ясый беләбез.

Күмәк бию. Утыралар.

Кар кызы. Балалар, мин сезгә бер табышмак әйтим әле. Җавабын уйлап әйтегез.

Килә ерак җирләрдән
Кар-бураннар туздырып.
Ел да олы капчыгына
Күчтәнәчләр тутырып.
Үзе шаян, сүзгә бай.
Ул кем була?..

Балалар. Кыш бабай!

Кар кызы. Әйе, ул минем бабакаем. Сез аны көтәсезме соң?

Балалар. Көтәбез.

Кар кызы. Менә мин дә бик көтәм. Нишләптер соңлады әле ул. Буран да чыгып тора иде, әллә адашты микән? Юлны табалмыйдыр әле. Әйдәгез, чистартып куйыйк әле. Аю, дусларым, менә сезгә көрәкләр, булышыгыз әле миңа.

Ике Аю булып киенгән бала көрәкләр белән бииләр, "юл тазарталар".

Кар кызы (шатланып). Ай, шундый чиста булды. Булмаса булган икән, якты булсын, фонарьлар да элеп куйыйк әле. Минем кечкенә дусларым-гномнар, менә сезгә фонарьлар.

Гномнар фонарьлар белән бииләр.

Соңыннан фонарьларны чыршыга эләләр.

Кар кызы (кайгырып). Һаман да юк. Балалар, чакырып карыйк әле. Ишетми калмас.

Балалар. Кыш бабай, Кыш бабай!

Залга "кар" йомарлап аталар. Кар кызы кирегә ыргыта. Тагын аталар.

Кар кызы. Мөгаен, бу Кыш бабай безнең белән шаярадыр. Әйдәгез әле, үзен дә кызык итик. Тотабыз да, чыршы артына качабыз. Эзләсен әле, хәйләкәр, шаян бабай.

Балалар чыршы артына качалар. Музыка астында Кыш бабай керә. Тукталып карап тора.

Кыш бабай. Искиткеч матур тирә-як. Ә бу чыршы, карап туймаслык чибәр булган. Тәки бәйрәмгә бизәп өлгерткәннәр бит. Кая соң әле үзләре, берәү дә юк. (Эзли, әкрен генә чыршы тирәли бара, балалар аның артыннан баралар. Кунаклар каршында туктый). Исәнмесез, кунаклар! Кая киткәннәр микән балалар, сез күрмәдегезме? Бернәрсә дә белмисезме? (Борчылып) Балаларны тапмасам, кире урманыма китәрмен инде. Әллә ничек булды әле бу. Ай-яй-яй.

Балалар. Без монда бит Кыш бабай!

Кыш бабайны уратып алалар, кочаклыйлар. Исәнләшәләр. Кыш бабай да аларны иркәли, сөя.

Кыш бабай. Ах сез, шаяннар. Менә бит Кыш бабагызны ничек кызык иттегез... Ә мин сезнең бакчага шундый ашыктым, шундый ашыктым...

Кар кызы. Ә үзең соңга калдың, бабакай.

Кыш бабай. Бер юлга кичерегез инде, Кыш бабагызны.

Кар кызы. Кыш бабай, ә бу чыршыны син җибәргән идеңме?

Кыш бабай. Мин булсам, ни әйтерсез. Ошыймы соң?

Балалар. Ошый.

Кыш бабай. Бигрәк матур бизәгәнсез,
Кабат-кабат сокланам.
Яшел чыршы тирәсендә
Җырлап алыйк, ичмасам.

Җыр "Кыш бабай". (М. Әндәрҗанова җыры)

1 бала. Кыш бабай, Кыш бабай,
Безнең белән дус бабай.
Йөзең якты, туның яхшы
Барыбызны коч бабай.

2 бала. Бер ел буе сагынып,
И көттек, көттек сине
Менә шундый зур үстек,
Танымассың да безне.

3 бала. Кыш бабай, алтыным,
Битләрең кызарган.
Әйдәле, бер биик,
Уздырып кызлардан.

Кыш бабай белән күмәк бию.

Кыш бабай. Бигрәк күңелле балалар...

Ә сез суыктан куркасызмы соң? Юкмы? Ягез әле, кулларыгызны сузыгыз.

Уен "Кулны туңдыру".

Кар кызы. Кыш бабай, тукта инде туңдырып бетерәсең бит.

Кыш бабай. һе-һе-һе. Ә үзегез суыктан курыкмыйбыз дигән буласыз. Хәзер мин сезне бик тиз җылытам. Минем музыкаль тылсымлы келәмем бар. Кем дә кем шул келәмгә баса, шул үзеннән-үзе биеп китә.

Уен "Тылсымлы келәм". Башта Кыш бабай үзе башкарып күрсәтә. Келәмгә бер аягын куя, музыка яңгырый. Аягын ала, туктый. Балалар келәмгә кереп басалар, музыка башлана. Ирекле бию. Бу уен чыршы алдында бара. Балалар утыралар.

Кыш бабай. Ай, балалар, шәп биедегез,
Инде бераз ял итегез.
Мин шигырьләр бик яратам,
Шигырьләр сөйләп китегез.

Аерым шигырьләр. Иң соңгы шигырьне куян сөйли.

Куян. Кыш бабай ул, усал бабай.
Колак, битне чеметә.
Мин барыбер туңмыймын,
Кыш бабайдан курыкмыймын.

Кыш бабай. Әле син мактанасыңмы? Менә мин сине хәзер тотам да туңдырам. (Куышалар. Кыш бабай тота алмый, кире килеп утыра). Ай, кызу, кызу. Эри башладым бугай.

Кар кызы. Балалар, өрәбез, Кыш бабайны суытабыз. (Балалар өрәләр. Кыш бабай йоклап китә). Менә сиңа, мә. Кыш бабай йоклап китте. Аннан башка ничек бәйрәм итик инде. Балалар, Кыш бабайны уятыйк әле. Әкрен генә килегез, музыка уйный башлагач, нык итеп кул чабыгыз. (Кыш бабай уяна, балаларны куа).

Кыш бабай. Ай, тагын кызу. Җилләр, җилләр, исегез, кар яудырып китегез.

Кар бөртекләре биюе.

Кыш бабай. Менә рәхәт булып китте.

Кар кызы. Кыш бабай, бүген безнең бәйрәмдә куяннар да бик күп. Аларның җырлыйсылары, бииселәре килә.

Куяннар бииләр. Балалар җырлап торалар.

Кыш бабай. Шундый оста, булган балалар. Бәйрәмегез бик ямьле. Миңа китәргә вакыт.

Кар кызы. Әй, Кыш бабай, хәйләкәр дә инде син. Балалар сиңа үзләренең бөтен һөнәрләрен күрсәттеләр. Ә син. Алай ярамый. Балалар да сине карап торсыннар әле, яле бие.

Кыш бабай бии.

Кыш бабай (сорый). Кыш бабагыз биедеме?

Балалар. Биеде.

Кыш бабай. Сезнең белән уйнадымы?

Балалар. Уйнады.

Кыш бабай. Шаярдымы?

Балалар. Шаярды.

Кыш бабай. Ә Кыш бабагыз нәрсәне онытты?

Балалар. Күчтәнәчләр.

Кыш бабай. Шул, шул. Менә мин аны монда куйган идем. (Чыршы артыннан эзләп киләләр. Бау күрә). Бу нинди бау. (Тартып карый). Булышыгыз әле, балалар. (Чанада Кар әбине тартып кертәләр).

Балалар Кар әби янына басалар.

Кар әби. Мин Кар әби, Кар әби,
Кердем сезгә урамнан.
Мине балалар ясады,
Әвәләп ап-ак кардан.
Борын минем кишердән,
Ике күзем күмердән.
Тишек чиләк башымда,
Торамын каравылда.
Тоттырдылар кулыма
Бик иске бер себерке.
Чакырмагач бәйрәмгә
Күрәсез, үзем килдем.

Кар кызы. Менә әйбәт булган. Кар әби белән уйныйк әле. (Кар аталар. Ул себеркесе белән йөзләрен каплый. Аннан сикереп тора).

Кар әби. Җитәр, җитәр туктагыз,
Сез миңа кар атмагыз.
Утырыгыз, барыгыз.
Биим менә, карагыз.

Кар әби биюе.

Кыш бабай. Әй, Кар әби, каравыл торудан нык туйгансың икән, биюдән туктатып булмый үзеңне.

Кар әби. Минем дә бит сезнең кебек күңел ачасым килә. Балаларны сөендерәсем килә.

Кыш бабай. Әле балаларын мин дә сөендерә алмадым. Күчтәнәчләремне югалттым.

Кар әби. Юк өчен кайгырма. Мин бит гади генә Кар әби түгел, тылсымлы Кар әби. Менә шушы кар йомарламында инде сезнең күчтәнәчләр. (Кар йомарламы күрсәтә).

Кыш бабай. Бу бит бигрәк кечкенә,

Кар әби. Ашыкма. Сабырлык кирәк, Кыш бабай. Мә әле, кызым (Кар кызына бирә) тәгәрәт әле.

Кар кызы тәгәрәтеп китә, чыршы артыннан зур йомгак тәгәрәтеп алып чыга.

Кар кызы. Менә ничек зурайды бу кар йомгагы.

Өчәүләп тәгәрәтәләр. Чыршы артыннан тагын да зур йомгак белән чыгалар.

Кыш бабай. Менә, ичмасам, йомгак та йомгак.

Кар әби. Бу бик серле кар йомгагы. Аның серен ачар өчен башта җырларга кирәк.

Кар кызы. Әйдәгез, балалар, җырлыйбыз.

Җыр. Чыршы (М.Мозаффаров көе. Ә.Ерикәй сүзләре)

Утыралар. Кыш бабай, Кар әби кар йомгагын ачалар. Анда күчтәнәчләр. Балаларга өләшәләр. Балалар рәхмәт әйтәләр.

Кыш бабай. Бик күңелле үтте бәйрәм.
Безгә кирәк китәргә.
Телим сезгә Яңа елда
Тагын да зур үсәргә.
Дус булыгыз хезмәт белән
Шатлык китерсен һәр көн.
Яңа елда мәрхәмәтле
Бәхетле булсын һәркем.



Кар әби. Сезнең кебек дус балалар
Артканнан арта барсын.
Бер елдан соң очрашырга
Тагы да безгә язсын.

Кыш бабай. Кар әби саубуллашып китәләр.

Кар кызы. Рәхмәт әйтик чыршыбызга
Матур бәйрәме өчен
Рәхмәт әйтик кунакларга
Килеп караган өчен.
Яңа елга, яңа юлдан
Нык басып бердәм керик.
Иң изге саф теләкләрне
Бер-беребезгә телик.

Музыка астында залдан чыгып китәләр.

<u>**ИСКӘРМӘ.**</u> *Тәрбиячеләрнең берсе кар кызы була, икенчесе алып бару, оештыру эшендә, балаларның һәр бер чыгышында катнаша.*

Сценарийны Гөлсинә Газиз кызы ГӘРӘЕВА язды.

Кыш бабай белән шаяру



- Кыш бабай, синең
Менә шундый бүрегең.
- Бүрегемне батырып кисәм,
Буран чыга күрерсең.

- Кыш бабай, синең
Менә шундый сакалың.
- Сакалымны сыпырып алып
Карлар яудырам тагын.

- Кыш бабай, синең
Менә шундый таягың.
- Таяк белән шакылдатсам
Биеп китәр аягың.



Син килгәнгә сөендек

Яшел чыршы, син килгәнгә
Сөендек.
Кара ничек матур итеп
Киендек.
Ләлә-лә, ләлә-лә
Матур итеп киендек.
Сиңа карап сокланабыз,
Җырлыйбыз.
Синең белән бергәләшеп
Уйныйбыз.
Ләлә-лә, Ләлә-лә.
Бергәләшеп уйныйбыз.



Бие әйдә, Кыш бабай



Килеп җитте Кыш бабай
Түргә әйдә, рәхим ит.
Яшел чыршы янында
Уйнап, биеп, җырлап кит.
Кушымта:
һоп-һоп, бас әйдә,
Күңелне күтәр, әйдә.

Синең кебек юмарт бабай,
Шаян бабай белмибез.
Елга бер генә киләсең
Биетми җибәрмибез.
Кушымта:

"Эврика" шәһәр мәдәният үзәгендәге очрашу-кичәдән без шундый теләк белән таралыштык.

Газетабызның дуслары һәм теләктәшләре күплеген күрсәткән матур кичә булды ул. Аны "Эврика" шәһәр мәдәният үзәге оештырды: баш мөхәррирбез Нәсимә Садыйкованы шәһәребез мәктәпләрендә татар теленнән белем биргән укытучылар белән очраштырды. Бу кичәдә сүз, башыннан ахырына хәтле гел газетабыз турында гына барды.



Очрашуның темасы да: "Көмеш кыңгырау"да шәһәребез мәктәпләрендә укучылар иҗаты" дип аталды бит.

Баш мөхәррир газетаның ничек чыга башлавын искә алды.

Укучылар иҗатыннан гына торган рубрикаларны, сәхифәләрне атады. Балалар иҗатын үстерергә ярдәм бирердәй конкурсларыбызга киң тукталды. Шулар арасыннан иң беренче булып "И туган тел, и матур тел" конкурсын атады ул. Габдулла Тукайның туган көненә багышлап үткәрелгән бу әдәби бәйгедә, кагыйдә буларак, бөтен шәһәр укучылары катнаша. Бу кичәгә "Шәм язмышы" исемле язмасы белән шушы конкурста I урынны алган, 20нче мәктәп укучысы Гөлнара Нәбиева да килгән иде. Ул очрашудагы кунаклар каршында үзенең шушы парчасын укыды.

Бик күп конкурсларыбызда катнашып, гел җиңүче булып килгән актив хәбәрчебез Земфира Давидова шигырьләре дә очрашуга җылылык һәм шигъри аһәң бирде.

Бик җитди очрашу булган икән бу, дип ашыгыч нәтиҗә ясамагыз. Уен-көлкегә дә урын күп булды бу кичәдә. Телгә оста, шаян сүзне үз күргән Гүзәл Шәйхетдинова (2нче мәктәп-гимназия) килгәч, уен-көлке, мәзәк, җор сүз ничек булмасын инде ул! Гүзәл "Көмеш кыңгырау"да чыккан мәзәкләрне, шигырьләрне гадәттәгечә бик оста укыды.

Тагы булсын иде мондый кичә!

Укытучы абыйлары һәм апалары рәхәтләнеп көлеп утырдылар. Гүзәлне кат-кат, сорап-үтенеп сөйләттеләр ул кичәдә!

Җырлы да булды ул очрашу. Шәһәребездә һаман саен нурлана, яктыра барган нәни йолдызларның берсе - Рузил Гатин бик матур җырлар башкарды.

Бу кичәдә газетабыз турында матурдан-матур фикерләр ишеттек. 10нчы мәктәптән Венера ханым Бәшәрова мәсәлән, болай диде:

- Чыга башлаганда "Укырлар микән бу газетаны?" дигән шик бар иде. Хәзер инде бернинди шик тә юк: "Көмеш кыңгырау"ның чыны киң таралды, аны балалар яраталар.



Газетаның баш мөхәрриренә, ул җитәкләгән коллективка яңадан-яңа уңышлар телибез.

Без мондый кичәнең булуына бик шатбыз. Шуңа да аны оештыруга фатихасын биргән "Эврика" директоры Рушания Кашировна Кулакова, татар бүлеге мөдире Гөлия Җиһаншевна Шәрәфиевага, очрашуны оештырам дип яныл-тырышып йөргән, шул максатта "Эврика" белән редакция арасына өр-яңа сукмак салган (күчермә һәм туры мәгънәсендә) Лилия Юнировна Газетдиновага чын күңелдән рәхмәт укыйбыз. Шагыйрь Мөдәррис Әгъләм шигырендәге: Булырмы икән тагы бу кичә?! Китеп булмый шуны белмичә!" дигән юлларны искә алып, "Булсын иде тагы шундый кичә!" дибез.

Рәсемнәрдә: күңелләрдә озак сакланырлык кичә күренешләре; Гүзәл Шәйхетдинова бик бирелеп мәзәк сөйли (сулда); Земфира Давидова шигырьләрен укый.

Фәрит Кәримов фотолары.

Айгөл, гөлле һәм Айгөлле шигырь илендә

"Көмеш кыңгырау" яңадан-яңа талантларны ача. Аларга үсәргә, канатларын ныгытырга ярдәм итә. 54нче мәктәп укучысы Айгөл Батыршинаның беренче шигырьләре безнең газетада дөнья күрде. Айгөл шуннан соң безгә даими рәвештә язып тора. Конкурсларыбызда катнаша, без үткәргән чараларга гел килә. Айгөл нәфис сүз остасы буларак та игътибарга лаек. Өстә атап үтелгән кичәбездә дә катнашты ул. Матур тавыш белән үз шигырьләрен укыды. Бүген сез Айгөлнең яңа шигырьләре белән танышыгыз.

Көз

Үтте ямьле көннәр, үтте җәйләр,
Килде вакыт: ява көзге яңгыр.
Кошлар китәр ташлап туган якны
Кыр болыннар ялгыз булып калыр.
Агачларда күренми бер яфрак,
Табигать тын: тала зур йокыга.
Бары тик җил, җәйне эзләгәндәй,
Йөрәккә үтеп керердәй сызгыра.
Күкләргә соры төсләр ингән
Кояш качкан болыт артына
Табигатькә карап, җиргә-күккә карап
"Әйе, көзләр җитте", - дип әйтергә була.

Әтием

Борылмыйча бардың алга
Горур адымнар белән.
Чын кеше иттең син безне
Тормышка өстәдең ямь.
Кулны тотып алып кердең
Матур, аяз көннәргә.
Китап булдың укыганда
Терәк булдың үскәндә.
Сабырлык тәрбияләдең
Өйрәттең эш сөяргә.
И ходаем, рәхмәт сиңа
Шундый әти биргәнгә.

Бакчасарай

Күгеңдә алтын кояшың
Балкый йөзек кашыдай.
Синдәгедәй алтын кояш
Юктыр ул, Бакчасарай.
Болында табигатеңдә
Бакчасарай - әтием туган авыл
Сокланып җырлый тургай,
Син үзең дә тургай кебек
Сайрыйсың, Бакчасарай.

Төн җитсә, йолдызларыңны
Чәчә күккә көмеш ай.
Төннәрең дә көнең кебек
Бит синең, Бакчасарай.
Зәңгәр чишмә тавышлары
Яңгырый бишек җырыдай.
Җыр иле вә моң иле син
Авылым - Бакчасарай.

Исәнмесез, хөрмәтле редакция! Сезнең газета көннән-көн күбрәк ошый бара. Зур рәхмәт Сезгә. Мин аның саннарын тәрбия сәгатендә дә, дәресләрдә дә кулланам. Балалар кызыксынып тыңлыйлар. Кызганычка каршы, әти-әниләр вакытында акча алмагач, газета-журналларга язылуны бик кирәк санамыйлар. Шулкадәр мавыктыргыч, олылар өчен четерекле сорауларны ачыклавы белән дә, үз йөзе булуы белән дә ошый сезнең газетагыз. Әле менә 6нчы сыйныф укучылары Кәҗә турындагы язмаларын китереп бирделәр. Берничәсен сезгә җибәрәм.

Сөмбелә АБДУЛЛИНА.

Әдәбият укытучысы. Яшел Үзән районы, Бишнә авылы.

Хәйләкәр кәҗә

Кәҗәбез бик хәйләкәр,
Күзләре гел түтәлдә.
Без юкта чамалаган:
Ашаган кәбестәне.

Сыйлангач, чыгып бара,
Әбием күреп ала.
Кулына чыбык ала.
Яратып сукрана.

Кәҗәбез бик хәйләкәр
Бик аптырап тормаган,
Тишектән чыгып качкан,
Әбигә тоттырмаган.

Ләйсән ГЫЙЛЬФАНОВА.

Ашады бар үләнне

Ачык калган ишектән
Кәҗә кергән бакчага.
Алмагачны кимергән,
Түтәлләрдә сыйланган.

Сөтләчем, син нишләдең?
Ярамый бер дә болай.
Сиңа үлән җыйдым бит,
Барып ерак басудан.

Алдына үлән куйдым,
Миңа карый күзләре.
Без сүзсез дә аңлаштык:
Ашады бар үләнне.

Айгөл ХӘЛИУЛЛИНА.

Безнең кәҗәләр кирәкле!

Кәҗә ул - йорт хайваны һәм кешеләрнең дусты дип саныйм мин. Хәзер авылларда кәҗәләр аз очрый. Әнием сөйләвенчә, элегрәк кәҗәне сыер урынына тотканнар. Сөте күп булмаса да, төрле авырулардан файдалы икән. Мамыгыннан бәйләгән шәлләр, оекбашлар, бияләйләр, җылы, мамыклы, йомшак була. Дустыбыз кәҗә кечкенә булса да, эче төш кенә. Дәү әти белән дәү әни дә файдалы дип асраганнар кәҗәне. Аның холкын, яхшы якларын әнием дә сагынып искә алырга ярата. Әйе, табигатьтә һәр нәрсәнең үз урыны бар икәненә мин тагын да күбрәк ышандым. Сезнең барыгызны да кәҗәләрне яратырга һәм сакларга чакырам.

Альбина НОВОСЕЛОВА.

"Болгар илем - гүзәл җирем"

Шәһәр балалар иҗаты үзәге үсеп килүче яшь буынны халкыбыз тарихы белән таныштыру нияте белән "Болгар илем - гүзәл җирем" программасын игълан итә.

Программаның төп максаты: гомуми белем бирү мәктәпләрендә милли тәрбия бирүне камилләштерү. Идел буе Болгар халкы тарихын, сәнгатен, мәдәниятен аңлатуны тирәнәйтү һәм пропагандалау.

Программаның эчтәлеге һәм үткәрү вакытлары:

I тур. "Көмеш кыңгырау" газетасының бүгенге санында басылган "Борынгы бабаларыбыз" уен-викторина сорауларына җавап бирү һәм уен-викторинаны ноябрь-январь айларында шәһәр балалар иҗат үзәгенең милли-мәдәният сәнгать бүлеге уздыра.

Белешмәләр өчен телефон: 56-91-15.

II тур. Шәһәребез мәктәпләрендә "Идел буе Болгар дәүләтенең үсеш тарихы" дигән тема астында рефератлар әзерләү. Үткәрү вакыты - октябрь-декабрь айлары.

III тур. Укучы балалар Шәһри Болгарга багышлап, үзләре иҗат иткән шигырьләр һәм хикәяләр конкурсы - октябрь-декабрь айлары.

IV тур: "Шәһри Болгар: кичә, бүген, иртәгә" темасы астында рәсемнәр конкурсы (октябрь-декабрь).

V тур. "Болгар батыры" яшүсмерләр арасында милли көрәш ярышы үткәрү урыны һәм вакыты ноябрь ае. Шәһәр балалар иҗат үзәге - милли ирекле көрәш бүлеге.

VI тур. "Чын күңелдән сөйләшүләр" исемле түгәрәк өстәл (Бөек Болгар белән бәйләнештә, элемтәдә булган иҗади коллективлар, язучылар, шагыйрьләр, күренекле вәкилләр белән сөйләшүләр. (Январь ае. Шәһәр балалар иҗат үзәгендә).

VII тур. Идел буе Бөек Болгар дәүләтенең таркалуы һәм Казан ханлыгы тормышын чагылдырган "Сөембикә ханбикә" исемле әдәби музыкаль кичә. Һәм бу кичәнең икенче бүлегендә "Борынгы бабаларыбыз уен-викторинасында җиңеп чыгучыларга бүләкләр тапшырыла.

Шәһәр балалар иҗат үзәге. Милли мәдәният сәнгать бүлеге. Март аенда уздыра.

VIII тур. "Исәнме, минем Болгарым", "Болгар илем - гүзәл җирем" шәһәр программасына нәтиҗә ясау. Программаның турларында җиңеп чыккан балаларны Болгар җирендә тантаналы төстә бүләкләү.

Уңышлар сезгә, дуслар!

Уен-викторина өчен сораулар

1. Ислам дине кабул ителгәнчегә кадәр Болгарда нинди дингә табынганнар. Бу чорда болгарлар әләменә нинди сурәт төшерелгән?

2. Идел буена болгарлар күчеп килгәнче нинди халыклар яшәгән?

3. Бөек Болгар дәүләтенең зур шәһәрләрен санап чыгыгыз. Аларның саны ничәгә җиткән?

4. Идел буйларына болгарлар кайсы җирләрдән, кайсы гасырда күчеп килә башлаганнар?

5. Болгарлар Европада беренче булып нинди һөнәрнең серенә төшенгәннәр һәм дә тагы нинди һөнәрләрне белгәннәр?

6. Болгар дәүләте рәсми рәвештә кайсы елны ислам динен кабул иткән?

7. Безнең ерак бабаларыбыз нинди кул эшләре белгәннәр, дөньяның гүзәллеген сәнгать теленә ничек күчерә алганнар? Бүгенге көнгә борынгыларның нинди сәнгать истәлекләре сакланып калган?

8. Чаллыда һәм аның тирә-юнендә моннан мең еллар элек кемнәр яшәгән?

9. Болгар дәүләтендә Ишкул хан кайсы елларда хакимлек иткән? Ишкул хан чорында кайсы илләр белән сәүдә иткәннәр.

10. 839-844 елларда кайсы хан Болгар дәүләте тәхетенә утыра һәм шул кыска гына чорда илгә нинди үзгәрешләр кертә?

11. Кубрат хан кайсы елларда яшәгән һәм аның турында ниләр беләсез?

12. Кайсы афәтле ел, кайсы илдә, кемнәргә болгарлар ашлык сатканнар?

13. Болгарларның гадәт вә йолалары?

14. Аксак Тимер гаскәрләре һөҗүменнән соң болгарлар белән руслар арасында ничә тапкыр сугыш булган һәм кайсы елларда?

15. Кол Гали кайсы гасырда яшәгән һәм нинди әсәре белән танылган?

16. Чаллы шәһәрендә яшәүче Болгар темасына иҗат итүче кайсы язучы һәм шагыйрьне беләсез? Әсәрләрен атагыз.

Викторинаның сорауларын Әлфия Нурулловна ГАРИФУЛЛИНА төзеде.

КАДЕРЛЕ БАЛАЛАР!

Ә сезнең "Яр Чаллы типографиясе" коммуналь предприятиесе турында ишеткәнегез бармы? Әйе-әйе, ЗЯБ бистәсендәге. Менә шушы типографиядә канцелярия товарлары сату буенча киоск эшли. Биредә **көндәлекләр, дәфтәрләр, каләм-карандашлар, бетергечләр, линейкалар,** кыскасы, дәрес өчен бөтен кирәк-ярак та бар. Бәяләре дә түбән. Тизрәк әти-әниләрегез белән киңәшегез дә безгә килегез.

Адресыбыз: *ЗЯБ бистәсе, Беренче Май урамы, 6нчы йорт. "Санэпидемстанция" тукталышына кадәр килергә.*

Белдерү

Яшь көрәшчеләрне көтәбез

1982-84нче елларда туган үсмерләр арасында "Көмеш кыңгырау" газетасы призына милли көрәш буенча шәхси һәм командалар арасында традицион республика турниры үткәрелә. Турнирның генераль спонсорлары - Бертуган Кашаповлар.

Турнир шушы елның 29-30 ноябрендә 3нче балалар һәм үсмерләр спорт мәктәбендә (ДЮСШ-3) үткәрелә. ("Тынычлык" проспектыннан 7,13, 22, 14э, 33э автобуслары белән "курчак театры" тукталышына кадәр барырга кирәк).

Килү көне - 28 ноябрь. Судьялар коллегиясе киңәшмәсе кичке сәгать 5тә була. (ДЮСШ-3 бинасында).

Бәйгедә 1982-84 елгы үсмерләр 40, 45, 50, 55, 60, 65, 70 кг һәм артыграк авырлыктагы категорияләр буенча катнашалар.

Врач раслаган заявкалар мандат комиссиясенә үлчәнгән көнне, ягъни 29 ноябрьда тапшырыла. Үлчәнү иртәнге 8дән 9га кадәр була.

Чемпионнар һәм призерлар кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә. Җиңгән командага тәкә бирелә.

Көмеш кыңгырау

Баш мөхәррир
Нәсимә САДЫЙКОВА

Рәссам - **Фаил Ислам**
Язмаларны компьютерда җыючы һәм урнаштыручы
Резидә Кариева

"Көмеш кыңгырау"ны оештыручылар һәм гамәлгә куючылар: халык депутатларының Чаллы шәһәр советы һәм шәһәр хакимияте.

"Көмеш кыңгырау" газетасы Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 466нчы номерлы таныклык белән теркәлде.

БЕЗГӘ КИЛЕГЕЗ, ХАТЛАР ЯЗЫГЫЗ: 423802, Чаллы шәһәре, ГЭС бистәсе, 8/7 "Б", 601 бүлмә "Көмеш кыңгырау" газетасы редакциясе.

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:

42-01-11 - баш мөхәррир,
42-32-49 - баш мөхәррир урынбасары,
42-63-63 - баш хисапчы,
42-22-19 - "Серебряный колокольчик" редакциясе, операторлар, 42-26-45 - мәктәпләр һәм хатлар бүлеге.

Редакциягә килгән хатлар рецензияләнми, кире кайтарылмый.

"Көмеш кыңгырау"дан алынган язмаларның чыганагын күрсәтү мәҗбүри.

Яңа ачылган татар балалары газетасына матди ярдәм күрсәтергә теләүчеләр өчен исәп-хисап счеты: ГКБ "Автоградбанк" 700161148/363410.

Газета компьютерда җыелды.
Офсет ысулы белән КП "Яр Чаллы типографиясе"ндә басылды.
Адресы: 1 Май урамы, 6.
Атнага ике тапкыр чыга.
Индекс 31700
Тираж 7905
Басарга кул куелды 14.11.97